Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советының тугызынчы утырышы

Пановка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

9 июль, 2021 ел № 21

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Пановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 25 декабрендәге 36 номерлы Пановка авыл җирлеге советы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Пановка авыл җирлеге уставы нигезендә **Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Пановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 25 декабрендәге 36 номерлы карары (2018 елның 5 мартындагы 83/37 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип санарга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев